**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2026 елның 07 июле** **54-РС номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ нчы Федераль законның 22 нче статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 нчы статьясы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ нчы Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турындагы кодексының 19 нчы статьясы, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 47 нче статьясы, Лаеш муниципаль районы Советының «Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 11 сентябрендәге 52-РС нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә һәм аны Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә ярашлы рәвештә 2026 елның 3 августында уздырырга (уздыру вакыты – 09.00 сәг., уздыру урыны – Лаеш муниципаль районы Советының кече залы). Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә претендентлардан конкурска документлар кабул итүне 2026 елның 10 июленнән 29 июленә кадәр (кертеп), ял һәм бәйрәм көннәреннән тыш, һәркөнне сәгать 8.00дән 17.00гә кадәр түбәндәге адрес буенча гамәлгә ашырырга: 422610, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, Первомайская урамы, 39 нчы йорт.

2.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатлыкны карау өчен конкурс комиссиясе составын (алга таба – конкурс комиссиясе) «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатлыкны карау өчен конкурс

комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 25 маендагы 332 нче Указы нигезендә (2025 елның 4 сентябрендәге редакциясендә), кушымта нигезендә расларга.

3. Конкурс комиссиясенә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздырырга, конкурс нәтиҗәләрен һәм кандидатлар турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына тәкъдим итәргә.

4.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турындагы белдерүне «Камская новь» район газетасында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, шулай ук «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең кадрлар составыннан идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында бастырып чыгарырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы рәисе урынбасары Т.П. Борһановага йөкләргә.

.

**Муниципаль район башлыгы-**
**Совет рәисе** **И.Ф. Зарипов**

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Советының
2026 елның «___» _____________ нче
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатлыкны карау өчен конкурс комиссиясе составы**

| № | Ф.И.О. | Эш урыны, вазыйфасы | Кем тарафыннан билгеләнгән | Комиссия составындагы статусы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Борһанова Татьяна Петровна | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башлыгы урынбасары | Лаеш муниципаль районы Советы тарафыннан | Комиссия рәисе |
| 2. | Солягин Артем Олегович | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары | Лаеш муниципаль районы Советы тарафыннан | Комиссия рәисе урынбасары |
| 3. | Вдовина Татьяна Васильевна | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар белән тәэмин итү һәм муниципаль хезмәт бүлеге нәчәлниге | Лаеш муниципаль районы Советы тарафыннан | Комиссия сәркатибе |
| 4. | Белов Александр Николаевич | Татарстан Республикасы Раисы каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты җитәкчесе | Татарстан Республикасы Раисы тарафыннан | Комиссия әгъзасы |
| 5. | Мөхәммәтшин Наиль Рәшит улы | Татарстан Республикасы Рәисенең территорияләр белән эшләү буенча идарәсенең баш советнигы | Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан | Комиссия әгъзасы |
| 6. | Самаренкин Дмитрий Анатольевич | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Казан май комбинаты» акционерлык җәмгыятенең Директорлар советы рәисе (килешү буенча) | Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан | Комиссия әгъзасы |